# Солдат хәтере

*Җиңү көненә багышлыйм*

Җиңү көне солдат хәтерендә,

Йөрәгендә калган зур эзләр.

Йөзләрендә тирән җыерчыклар,

Бик күпләрне күрде ул күзләр.

Сугыш кырларында, окопларда,

Үтте аның биш ел гомере.

Атакага барган иптәшләре,

Һәлак булды- ташсыз кабере.

Ап-ак башын иеп тора солдат,

Мәңге янган утның каршында.

Күзләреннән тама авыр яшьләр,

Бүгенгедәй алар хәтердә.

Хәтер учагында яна солдат,

Намуслы ул иле каршында.

“Балаларым күрмәсеннәр сугыш”,

Уйлый солдат алар хакында.

*Мехаматнур Нәҗметдинов, 2021 ел, апрель.*